ТР Зәй муниципаль районы “Каенкай” балалар бакчасы

# 15 нче февраль – ватанпәрвәр – шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне әдәби кичә

Уртанчылар төркеме

Тәрбиячеләр:

Нәҗмиева В.М.

15 нче февраль, 2016 ел

# герой – шагыйь Муса Җәлил



# Тормыш юлы һәм иҗаты

Муса Җәлил 1906 елның 15 февралендә Оренбург өлкәсе Мостафа авылында гаиләдә 6 нчы бала булып дөньяга килә. 6 яшьтән укырга керә. Бәләкәй чактан бик зирәк була. Ул рәсем ясарга, уйнарга ярата. Муса бик хәрәкәтчән була.

Беренче шигырен М Җәлил 9 яшендә яза. 1922 нче елда Казанга килә, укырга керә. Мәскәүдә “Кечкенә иптәшләр” дигән балалар журналында редактор булып эшли. Бик күп шигырьләр иҗат итә, шигырьләренә көйләр языла. Шигырьләре төрле телләргә тәрҗемә ителә.


# Муса Җәлил “Күке”

Калын урманда,
Гел кичкә каршы,
Ишетелә моңлы тавышы:
- Кәккүк, кәккүк,
- Кәккүк, кәккүк!
Ул ялгыз яши,
Чыгармый бала,
Менә шунлыктан
Ямансу аңа!
- Кәккүк, кәккүк,
- Кәккүк, кәккүк!



# Муса Җәлил “Әтәч”

Таң ата бугай,
Әтәч кычкыра:
– Кикри-күк,
Кикри-күк!
Йә сузып кына,
Йә бик еш кына:
– Кикри-күк, Кикри-күк!
Без дә уяндык
Әтәч тавышына:
– Кикри-күк,
Кикри-күк!
Бакчага килдек
Ашыга-ашыга:
– Кикри-күк, Кикри-күк!



М.Җәлил үзе туып- үскән якның табигатенә бик гашыйк кеше булган. Кош – корт, җәнлекләргә багышлап, шигырьләр иҗат иткән.

## М.Җәлил “Куян”

Куян салкыннан
Туңган, куырылган,
Башы салынган,
Колагы шиңгән.
Әйдәгез, дуслар,
Аны терелтик,
Җылы бүлмәгә,
Бакчага илтик.
Куян уянды
Куркып уйланды,
Чабып югалды.
Әйдәгез, дуслар,
Кырны, урманны,
Чүлне актарып,
Табыйк куянны



М.Җәлил бала чакта бик хәрәкәтчән булган. Ул төрле уеннар уйнарга яраткан.

**“Ак куянкай” уены**

Ап- ак куян утыра
Колакларын селкетә
Менә шулай, менә шулай,
Колакларын  селкетә,
Аңа тик тору кыен,
Җылыта ул тәпиен,
Куян тик торса туңа
Сикергәли ул шуңа.
Һап, һап, һап.



# М. Җәлил «Маэмай»

Минем бар бер маэмаем
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...



# М.Җәлил “Карак песи”

Чоландагы ак майга
Иялəшкəн күселəр.
Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигə.
– Мияу, мияу, пескəем!
Бар əле син чоланга!
Майны сакла күседəн,
Оясыннан чыгарма!
Песи күргəч, күселəр
Койрыкларын кыстылар.
Йөрмəделəр чабышып,
Ярыкларга постылар.
– Мияу, мияу, пескəем!
Колак салдың сүземə.
Каравылдан бушагач,
Сөт бирермен үзеңə!
Иртə белəн майга дип
Керсəм, күзем акайды:
Явыз песи берүзе
Ялт иттергəн акмайны!
– Мияу, мияу, пескəем!
Хыянəтче икəнсең.
Саклый торган маеңны
Үзең ашап беткəнсең!



# М.Җәлил « Кызыл ромашка»



# Муса Җәлил “Кызыма”



Ìóëüòêóëüò- 'Ìàëåíüêèìè øàãàìè ê Âåëèêîé ïîáåäå'.mp4

Муса Җәлил исеме дөньяда яшәүче һәр халыкка билгеле. Аның исеме белән урамнар, бистәләр, опера театры аталган. Аның батырлыгын истәлегенә һәйкәл куелган





# Р.Корбан «Песня о Мусе Джалиле»

Муса Джалиль, Муса Джалиль,
Народный наш герой
Бессмертно его имя,
Вечная его  слава!
Песни писал наш Муса,
Его оружием было- перо.
С приходом врага
На автомат поменял он перо!

